**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**02.10.2020** г.Казань **№ 103од**

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерам:

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 2 октябрендәге 103од номерлы боерыгы белән расланган

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 2 ноябрендәге 01-02/685 номерлы административ регламентына (2018 елның 21 сентябрендәге 105од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 30 ноябрендәге 158од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы боерыклар белән кертелгән 2016 елның 13 февралендәге 01-02/55 номерлы, 2016 елның 29 мартындагы 01-02/115 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 01-02/48 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 50од номерлы үзгәрешләр белән) (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

«1.3.2. Министрлыкның җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлегенең (алга таба - Бүлек) телефоннары: (843) 222-60-87, 222-60-89, 222-60-90, 222-60-91.»;

1.5 пунктның җиденче абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза формасы әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада бирелгән.»;

2 бүлектә:

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза (әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада күрсәтелгән формада);

гариза бирүченең шәхесен ачыклаучы документ күчермәсе;

гариза бирүче вәкиленең гариза бирүче исеменнән гамәл кылу вәкаләтләрен таныклый торган документ;

Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә тапшырылырга яисә почта аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә мөмкин»;

2.7 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документларны кабул итүдән баш тарту өчен гаризаның билгеләнгән формага туры килмәве нигез булып тора.»;

Административ регламентка кушымтада (белешмәлектә):

«Татарстан Республикасы Ютиция министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 222-60-03 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлеге башлыгы | (843) 222-60-87 | Gulnara.Kasymova@tatar.ru |
| Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | (843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru |

Административ регламентка түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ кушымта өстәргә:

Татарстан Республикасында<br>административ-территориаль берәмлекләр<br>һәм торак пунктлар реестрыннан<br>өземтә яки соралган мәгълүматның<br>булмавы турында белешмә бирү<br>буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең<br>админисратив регламентына<br>$1^1$ нче кушымта

форма

_____________________________________________
(дәүләт хезмәтен күрсәтүче

_____________________________________________
органның исеме)

_____________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда) – физик зат өчен

_____________________________________________
(туган елы)

_____________________________________________
(паспорт сериясе һәм номеры, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

_____________________________________________
гариза бирүченең исеме – юридик зат өчен, ИНН

_____________________________________________

_____________________________________________
(гариза бирүченең почта адресы,

_____________________________________________
электрон почта адресы (адреслары – гариза бирүче теләге буенча)

_____________________________________________
(элемтә өчен телефон номеры (номерлары) - гариза бирүче теләге буенча)

_______________________

_____________________________________________
вәкиле исеменнән

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында
гариза

Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрыннан __________________________________________________________________________
(административ-территориаль берәмлек һәм (яки)
_____________________________________________________________________________________
торак пункт исеме күрсәтелгән мөрәҗәгать )
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
мөнәсәбәттә мәгълүмат бирүегезне сорыйм.

Кушымталар:
1.____________________________________________________________________________
2.____________________________________________________________________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызландыру, блоклау, юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

_____________ ___________________________ ___________________________________
(дата) (гариза бирүченең/вәкилнең имзасы) (Ф.И.Ә.и.)».

2. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрыннан өземтә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2016 елның 22 мартындагы 01-02/108 номерлы боерыгы белән расланган (2017 елның 2 июнендәге 01-02/48 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 50од номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге 105од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 18 ноябрендәге 154од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

1 бүектә:

1.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Министрлыкның җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең (алга таба – Бүлек) телефоннары: (843) 222-60-73, 222-60-75, 222-60-76, 222-60-80.»;

1.5 пунктның дүртенче абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза формасы әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада бирелгән.»;

2 бүлектә:

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза (әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада күрсәтелгән формада);

гариза бирүченең шәхесен ачыклаучы документ күчермәсе;

гариза бирүче вәкиленең гариза бирүче исеменнән гамәл кылу вәкаләтләрен таныклый торган документ;

Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән кәгазьдә тапшырылырга яисә почта аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә мөмкин.

Гаризада Регистрдан гариза бирүчегә бирү өчен кирәкле мәгълүматлар исемлеге күрсәтелә.»;

2.7 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документларны кабул итүдән баш тарту өчен гаризаның билгеләнгән формага туры килмәве нигез булып тора.»;

Административ регламентка кушымтада (белешмәлектә):

«Татарстан Республикасы Ютиция министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 8(843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 8(843) 222-60-03 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге башлыгы | 8(843) 222-60-73 | Rauf.Garipov@tatar.ru |
| Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | 8(843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru»; |

Административ регламентка түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасының
муниципаль норматив хокукый
актлары регистрыннан
өземтә бирү буенча дәүләт
хезмәтен күрсәтүнең
админисратив регламентына
$1^1$ нче кушымта

____________________________________
(дәүләт хезмәтен күрсәтүче
____________________________________
органның исеме)

_______________________________
(физик затлар өчен: ФИӘ.и.,
яшәү яки тору урыны адресы,
почта һәм (яки) электрон адрес

_______________________________
(юридик затлар өчен: оешманың исеме,
почта һәм (яки) электрон адрес

_______________________________
(элемтә өчен телефон номеры (номерлары)

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында
гариза

Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары регистрыннан өземтә бирүегезне сорыйм.

Регистрдан бирү өчен соратып алына торган мәгълүматлар исемлеге:

1. ______________________________________________________________;
2.______________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызландыру, блоклау, юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

_____________ ____________________________ ___________________________________
(дата) (гариза бирүченең/вәкилнең имзасы) (Ф.И.Ә.и.)».

3. Юридик затлар исемнәрендә Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2016 елның 8 декабрендәге 01-02/306 номерлы боерыгы белән расланган административ регламентында (2017 елның 2 июнендәге 01-02/48 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 50 од номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге 105од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 149од номерлы, 2020 елның5 августындагы 75од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Административ регламент):

1 бүлектә:

1.3.2 пунктның түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге (алга таба – Бүлек) телефоннары: (843) 222-60-41, 222-60-45.»;

1.5 пунктның дүртенче абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза формасы әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада бирелгән.»;

2 бүлектә:

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «биш көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әлеге Регламентка $1^1$ кушымтада бирелгән формадагы гариза;»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында булган һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомстволарндагы оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче аларны бирү хокукына ия булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны бирү тәртибе; | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алар турында Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар гариза һәм документлар керү датасына Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелмәгән юридик затның, оешманы гамәлгә куючының (гамәлгә куючыларның) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә) булуы (булмавы) турында белешмәләр алына.<br>Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган документлар һәм мәгълүмат бирүне яки гамәлләр кылуны;<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, | Нигезләмәнең $4^1$ пункты»; |

| | | |
|---|---|---|
| | башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат бирүне. | |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Административ процедураларны (гамәлләрне) башкаруның составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган гаризаны язу һәм документларны рәсмиләштерү буенча да ярдәм күрсәтү;

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

документларны карау, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запрос, дәүләт органнарына һәм оешмаларга запрослар җибәрү;

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар чыгару, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мәҗбүри булган гариза язу һәм документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Гариза язучы Министрлыкка язма формада, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://www.minjust.tatarstan.ru) электрон хәбәр җибәреп яки дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен урындагы затка шәхсән мөрәҗәгать итә ала.

Бүлек белгече гариза бирүчегә шул исәптән тәкъдим ителгән документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар, гариза язучы шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ул мөрәҗәгать иткән көнне, гариза язма формада яки электрон юл белән кергәндә - гариза кергән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документларның составы, формасы буенча һәм гариза бирүчегә рөхсәт бирү һәм ярдәм күрсәтүгә караган башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза язучы шәхсән (вәкиле аша) кәгазьдәге вариантта яки Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе (ttp://www.minjust.tatarstan.ru) аша яки почта аркылы Министрлыкка әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән гаризаны китерә (юллый).

3.3.2. Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге (алга таба - Документлар әйләнеше бүлеге) гамәлгә ашыра:

гариза һәм документларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше бердәй ведомствоара системасында (алга таба - электрон документлар әйләнеше) кабул итә һәм терки;

гариза Татарстан Республикасы юстиция министры яки министр вазыйфаларын башкаручы зат (алга таба – министр), һәм министрның беренче урынбасары яки аның вазыйфаларын башкаручы зат (алга таба – министрның беренче урынбасары) тарафыннан каралганнан соң тиешле документлар теркәлгән гаризаны (ул кәгазь вариантта кергән очракта) электрон документлар әйләнеше аша Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән (гариза почта аркылы кергән) көнне гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлеккә юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Документларны карау, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.4.1. Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында нигезле сәбәпләр күрсәтелгән хат проекты әзерли һәм хат проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына (ул булмаганда - аның вазыйфаларын башкаручы затка) (алга таба - Бүлек башлыгы) юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында Бүлек башлыгына килештерергә юлланган хат проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы хат проектын килештерә һәм аны килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура хат проекты Бүлек белгеченнән кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган хат проекты.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары хат проектын килештерә һәм аны имзалау өчен министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура хат проекты Бүлек башлыгыннан кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен министрга юлланган хат проекты.

3.4.4. Министр дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы хатны имзалый һәм аны Документлар әйләнеше бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура хат проекты имзалауга кергән көннән бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм Документлар әйләнеше бүлегенә юлланган хат.

3.4.5. Документлар әйләнеше бүлеге белгече:

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы хатны терки һәм аны гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән тапшыра (юллый).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы хат имзаланган көннән бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында теркәлгән һәм гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) хат.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запрос, дәүләт органнарына һәм оешмаларга запрослар җибәрү.

3.5.1. Бирелгән гаризада һәм документларда юридик затның Нигезләмәнең 3 пунктындагы икенче-бишенче абзацларында билгеләнгән критерийларның кайсына да булса туры килүе турында белешмәләр булган очракта, бүлек белгече:

электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба - ВЭХС) ярдәмендә юридик затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу (булмау) турында мәгълүмат бирү турында запросны Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрә;

әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән белешмәләрне раслау максатларында дәүләт органнарына яисә оешмаларга запрос проектын әзерли һәм запрос проектын Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә;

әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бүлеккә гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә юлланган, ВЭХС аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре соратып алына торган белешмәләрне закон белән билгеләнгән срокта тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән ведомствоара запроска җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр.

3.5.3. Бүлек башлыгы әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән запрос проектын килештерә һәм аны министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар проект Бүлек белгеченнән кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрелгән запрос проекты.

3.5.4. Министрның беренче урынбасары запрос проектын килештерә һәм аны имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар проект Бүлек башлыгыннан кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм министрга кул куюга җибәрелгән запрос проекты.

3.5.5. Министр запроска кул куя һәм аны Документлар әйләнеше бүлегенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар проект имзалау өчен кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган һәм Документ әйләнеше бүлегенә җибәрелгән запрос.

3.5.6. Документлар әйләнеше бүлеге белгече:

запросны терки һәм аны тиешле дәүләт органына яки оешмага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар запроска кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.

3.5.7. Дәүләт органы яисә оешмасы закон белән билгеләнгән срокта запросны карый. Запросны карау срогы дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына кертелми.

3.6. Рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар чыгару.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә алынган белешмәләр нигезендә:

юридик затка рөхсәт бирү турында күрсәтмә проектын (билгеләнгән критерийларга туры килү турында беешмәләр расланган яки Нигезләмәнең 3 пунктындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы бәяләмәсе булган очракта (алга таба - бәяләмә), шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда, яки рөхсәт бирүдән баш тарту очрагында (билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәү турында белешмәләр расланмау яисә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау очрагында), шулай ук аңлатма хаты проектын әзерли һәм аларны Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә. Аңлатма хатында рөхсәт бирүдән баш тарткан очракта баш тарту сәбәпләре аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Бүлеккә кергән көннән ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында күрсәтмә проектлары һәм Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән хатлар.

3.6.1. Бүлек башлыгы рөхсәт бирү яки рөхсәт һәм хат бирүдән баш тарту турында күрсәтмә проектларын килештерә һәм проектларны министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченнән проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектлары һәм хатлар.

Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм министрның беренче урынбасарына

3.6.2. Министрның беренче урынбасары рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектларын һәм хатларны килештерә һәм проектларны имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек башлыгыннан проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары белән килештерелгән һәм министрга кул кую өчен юлланган рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проекты һәм хат.

3.6.3. Министр рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарга һәм хатка кул куя һәм аларны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карар проекты һәм хат имзалауга кергән көннән бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кул куелган карар һәм хат.

3.6.4. Бүлек белгече рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарга номер, дата куя һәм карарның күчермәсен әзерли. Карарның күчермәсе хат белән бергә Документлар әйләнеше бүлегенә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарга һәм хатка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Документлар әйләнеше бүлегенә җибәрелгән рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар күчермәсе һәм хат.

3.6.5. Документлар әйләнеше бүлеге белгече:

хатны терки һәм рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарның күчермәләрен кушып, гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә җибәрә (бирә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар рөхсәт бирү яки рөхсәт һәм хат бирүдән баш тарту турындагы карарга һәм хатка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында гариза бирүчегә җибәрелгән (бирелгән) күрсәтмәнең күчермәсен кушып теркәлгән хат.

3.6.6. Нигезләмәнең 3 пунктындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы бәяләмәсе булган очракта, Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кергән көнгә юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелмәгән оешманы гамәлгә куючыга (гамәлгә куючыларга) карата, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр бирү хакында Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә ВЭХС аша запрос җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлеккә гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләр белгечләре СМЭВ аша кергән запрос нигезендә, законда билгеләнгән срокта соратып алына торган мәгълүматларны тапшыралар.

Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре ВЭХС аша кергән соратып алына торган белешмәләрне закон белән билгеләнгән срокта тапшыралар.

3.6.7. Алга таба булган административ процедуралар әлеге Регламентның 3.6-3.6.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

Министрның рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарын кабат рәсмиләштерү алдарак бирелгән карарда җибәрелгән техник хатаны (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) төзәтү белән бәйле рәвештә башкарыла.

Карарны кабат рәсмиләштерү ирекле формада язылган һәм теркәлгән, әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе белән бирелә торган (гаризаның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән) гариза нигезендә гамәлгә ашырыла. Гаризага гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең техник хата белән булган нәтиҗәсе буларак бирелгән карар күчермәсе, шулай ук юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе дә теркәлә.

3.7.1. Документлар әйләнеше бүлеге белгече:

электрон документлар әйләнешендә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра;

гаризаны электрон документлар әйләнешендә министр һәм министрның беренче урынбасары караганнан соң гаризаны теркәлгән документлар белән бергә (кәгазь документлар булганда) Бүлекккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән бер көн эчендә башкарылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хатаның төзәтелүе турындагы кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә тапшырылган гариза.

3.7.2. Бүлек белгече:

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында техник хата төзәтелгән карар проектын әзерли;

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза Бүлеккә кергән көннән бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган карар проекты.

3.7.3. Бүлек башлыгы карар проектын килештерә һәм аны килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура проектлар Бүлек башлыгыннан кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган карар проекты.

3.7.4. Министрның беренче урынбасары рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерә һәм аны имзалау өчен министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура проект Бүлек башлыгыннан кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен министрга юлланган карар проекты.

3.7.5. Министр рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кабат рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм аны Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура карар проекты имзалауга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кабат рәсмиләштерелгән һәм расланган карар.

3.7.6. Бүлек белгече:

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кабат рәсмиләштерелгән карарга беренчел карар теркәлгән номерны бирә, беренчел карарның датасын куя һәм карарның күчермәсен ясый;

гариза бирүчегә техник хатаны төзәтү яки дәүләт хезмәтен күрсәтүне сораган гаризада күрсәтелгән ысулны кулланып һәм гариза бирүченең теләге буенча документның әзерлеге хакында хәбәр итә:

әгәр дә гариза бирүче аны шәхсән кулына алырга теләк белдергән булса, кабат рәсмиләштерелгән карарны бирү көне һәм вакыты турында белдерә;

карарның күчермәсен, гариза бирүчегә юлласыннар өчен, Документлар әйләнеше бүлегенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар кабат рәсмиләштерелгән карар имзаланган көнне гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән карар. Карар күчермәсен тапшыруның гариза бирүче белән килештерелгән ысулы.

3.7.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең техник хата төзәтелгән нәтиҗәсен тапшыру.

Документлар әйләнеше бүлеге белгече рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарның күчермәсен гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән тапшыра (юллый).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) техник хата төзәтелгән карар күчермәсе.»;

Административ регламентка кушымтада (белешмәлектә):

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 222-60-02 | Aynur.Galimov@tatar.ru |
| Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы | (843) 222-60-41 | Elmira.Slepneva@tatar.ru |
| Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | (843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru»; |

Административный регламентка түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ кушымта өстәргә:

«Юридик затлар исемнәрендә Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына
$1^1$ нче кушымта

форма

____________________________________________
(дәүләт хезмәтен күрсәтүче

____________________________________________
органның исеме)

______________________________
гамәлгә куючы – физик затның
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда),
юридик зат булганда – ИНН ,оештыру-хокукый
формасы, исеме)

______________________________

(теркәлү/урнашу урыны адресы)

________________________________________

(элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы)

Юридик затлар исемнәрендә Татарстан Республикасының рәсми атамаларын файдалануга рөхсәт бирү турында гариза

Исемдә

____________________________________________________________________________

(оешманың исеме, урнашу урыны адресы, телефон номеры һәм электрон почта адресы)

____________________________________________________________________________.

(«Татарстан Республикасы», «Татарстан» атамаларын яки бу атамалардан чыгарылган сүзләр һәм кыскартылмалар)

файдалануга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Кушымталар:

__________________________________________________________

__________________________________________________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызландыру, блоклау, юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

______________________________________________ ______________________________

(гамәлгә куючы – физик затның, гамәлгә куючы вәкиленең– юридик затның имзасы) (имзаның тулы язылышы)

________________

4. Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территориясендә халык каршында чаралар үткәрүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 18 октябрендәге 01-02/125 номерлы карары белән расланган (2018 елның 5 июнендәге 50од номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге 105од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 11 декабрендәге 162од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) административ регламентында (алга таба - Административ регламент):

1 бүлекнең 1.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлегенең (алга таба – Бүлек) телефоннары: (843) 222-60-82, 222-60-85.»;

2 бүлекнең 2.5 пунктында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының егерменче абзацында «2013 елның 6 апреленнән» сүзләрен «2011 елның 6 апреленнән» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентка кушымтада (белешмәлектә):

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 222-60-03 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлеге башлыгы | (843) 222-60-82 | Mayya.Pashkova@tatar.ru |
| Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | (843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru». |

5. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 26 октябрендәге 137од номерлы административ регламентында (2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 9 декабрендәге 161од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Админитсратив регламент):

1 бүлекнең 1.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге (алга таба – Бүлек) телефоннары: (843) 222-60-47; (843) 222-60-60.»;

2 бүлектә:

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның

5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешманың булмавын раслаучы документлар, тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына гариза бирүче турында гариза бирүче документлар тапшырган айның беренче числосына язманы кертү факты.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган документлар һәм мәгълүмат бирүне яки гамәлләр кылуны;

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат бирүне.

2.8 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип санарга;

3 бүлектә:

3.4 пунктта:

3.4.1 пунктчаның дүртенче абзацында «проект» сүзен «проектлар» сүзенә алмаштырырга;

3.4.4, 3.4.5 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Министр аңлатма хатын имзалый, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә проектларын килештерә. Имзаланган аңлатма хаты, бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы килештерелгән нигезле белешмә проектлары Оештыру бүлегенә юллананалар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура күрсәтелгән проектлар килештерү өчен министрга кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм теркәү өчен Оештыру бүлегенә бирелгән бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белешмә белән булган аңлатма хаты.

3.4.5. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш

тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатын теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хаты министр тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшырылган бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хаты.»;

3.4.6 һәм 3.4.7 пунктчаларны үз көчен югалткан дип санарга;

3.5.1 пунктчаның өченче абзацында «хаты» сүзе алдыннан «бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма» сүзләрен өстәргә;

3.7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмәне яңадан рәсмиләштерү теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла (тәкъдим ителгән форма әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән), ул әлеге Регламентның 3.3.1 пунктчасында күрсәтелгән ысулларның берсе белән бирелә. Гаризага гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән һәм анда техник хата җибәрелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә, шулай ук, документлар мөрәҗәгать итүче вәкиле аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы ышанычнамә дә кушып бирелә»;

Административ регламентның 3.7.1 пунктчасында һәм аннан соң тексты буенча тиешле төрләнешләрдә һәм саннарда «мөрәҗәгать» сүзен «гариза» сүзенә алмаштырырга;

3.7.8, 3.7.9, 3.7.10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.8. Министр яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатына кул куя һәм аны Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен министрга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр тарафыннан кул куелган һәм Бүлеккә юлланган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хаты.

3.7.9. Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүчегә техник хатаны төзәтү турында гаризада яки дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, документның әзерлеге турында хәбәр итә, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатын теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар министр тарафыннан яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатына кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен Оештыру бүлегенә тапшырылган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хаты.

3.7.10. Оештыру бүлеге белгече:

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатын терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (бирә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар министр тарафыннан яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хатына кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән (бирелгән) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белешмә белән булган аңлатма хаты.»;

3.7.11, 3.7.12 пунктчаларны үз көчләрен югалтка дип санарга;

Административ регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль ориентлашкан коммерцияле<br>булмаган оешмалар тарафыннан<br>күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы<br>хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән<br>критерийларга туры килүләре турында<br>бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте<br>күрсәтүнең административ регламентына<br>2 нче кушымта<br>(тәкъдим ителә торган форма)

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган<br>оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр<br>сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр<br>бирүдән баш тарту турында нигезле белешмә

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма тарафыннан

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәлү номеры)

күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр

____________________________________________________________________________;

____________________________________________________________________________;

__________________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәт аталышы)

сыйфатларының билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килмиләр:

__________________________________________________________________;
__________________________________________________________________;
__________________________________________________________________.
(критерийларга туры килмәве күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Юстиция министры

_____________ ______________ _______________________

М.У. (дата) (имза) (Ф.И.Ә.и.)».

Административ регламентка кушымтада (белешмәлектә):

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-60-00 | minjust@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 222-60-02 | Aynur.Galimov@tatar.ru |
| Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге башлыгы | (843) 222-60-49 | Ilfat.Mingalimov@tatar.ru |
| Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге башлыгы | (843) 222-60-07 | Farida.Nurieva@tatar.ru |

Административ регламентка түбәндәге эчтәлектәге 3 нче кушымтаны өстәргә:

«Социаль ориентлашкан коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан

күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы
хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән
критерийларга туры килүләре турында
бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

______________________________________
(дәүләт хезмәтен күрсәтүче
________________________________________
органның исеме)
______________________________
______________________________

(оешманың исеме, почта һәм (яки) электрон адрес,
телефон номеры (булганда)

Техник хатаны төзәтү
турында гариза

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәдә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле аңлатма хатында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Документта _____________________________________________________
_______________________________________________________________
(бирелгән документның исеме)
диелгән.

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка тиешле үзгәрешләрне кертүегезне үтенәм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Документның әзерлеге турында түбәндәге алым белән белдерүегезне үтенәм
_______________________________________________________________
(белдерү алымы)
______________ _______________________ (_________________________________)
(дата) (имза) (Ф.И.Ә.и.)